ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» ноябрь 2022 ел № 277

2023 елга Әгерҗе муниципаль районының сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, "Татарстан Республикасының сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы “Әгерҗе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы белән, 2023 елга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәгенең исәп хисапларына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2023 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында сәнгать-эстетик юнәлешле мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнарны расларга.

2. 2023 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында Балаларга сәнгать-эстетик юнәлешле өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга төзәтү коэффициенты 0,65 күләмендә тәшкил итә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны 2023 елга бюджет язмасында әлеге максатларга каралган чаралар чикләрендә тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми

сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru).

5. Бу карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы** **Р. Р. Шәрипов**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 11.11.2022 елнын 277 номерлы карары белән расланды

**2023 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында өстәмә белем бирү өстәмә белем бирү сәнгать-эстетик юнәлешле мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар**

| Өстәмә белем бирү программасынын юнәлеше | Территориаль урнашу | Норматив чыгымнар (бер укучыга елына сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | дүрт еллык уку вакыты | биш еллык уку вакыты | жиде еллык уку вакыты | иртә һөнәри ориентация |
| Музыкаль сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 74 988 | 85 669 | 110 026 |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | | | 79 714 | 91 055 | 116 878 |
| Сынлы сәнгать | шәһәр җирлеге | | 39 699 | | 35 247 | 84 588 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 42 126 | | 37 425 | 89 801 |
| Хореография сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 83 632 | 68 869 | 252 446 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 88 953 | 73 250 | 268 494 |
| Гомуми эстетик сәнгать | шәһәр җирлеге | | | 35 168 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 37 395 | | |
| Фольклор сәнгате | шәһәр җирлеге | | | 76 896 | 73 832 | 118 624 |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 81 803 | 78 547 | 126 162 |
| Эстрада джаз сәнгате | шәһәр җирлеге | 115 796 | | 111 004 | | 182 027 |
| Эстрада джаз сәнгате | авыл җирлеге | 123 091 | | 118 014 | | 193 471 |
| Театр сәнгате | шәһәр җирлеге | 59 697 | | 55 573 | 55 492 | 83 712 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 63 434 | | 59 063 | 58 977 | 88 859 |